Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

29 гыйнвар, 2021 ел                                                                                    № 2

Мәет җирләү буенча хезмәтләр
күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең кушымта итеп бирелгән бәясен расларга.

2. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеген бирүгә тарифларны раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2020 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы Пимәр авыл җирлеге башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районының
Пимәр авыл җирлеге башлыгы                                                                Р.Р. Гиматдинов

Кушымта № 1
Питрәч муниципаль районының
Пимәр авыл җирлеге башкарма
комитеты карары белән расланды
29 гыйнвар, 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Пимәр авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү
буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәет җирләү өчен табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1801,89 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (калдыкларын) зиратка китерү | 415,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4207,25 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Кушымта № 2
Питрәч муниципаль районының
Пимәр авыл җирлеге башкарма
комитеты карары белән расланды
29 гыйнвар, 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлегендә
2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча
гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү өчен | 334,94 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1466,95 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (калдыкларын) зиратка китерү | 415,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4207,25 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |